Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Котлы Бөкәш авыл җирлеге Советы

**КАРАР № 4**

Котлы Бөкәш авылы 2026 елның 14 апреле

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлеге Советының 2018 елның 07 маендагы «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең даими нигездә муниципаль вазыйфа биләүче затларына акчалата бүләкләүләр, вазыйфаи айлык хезмәт хакы, айлык һәм башка өстәмә түләүләр күләмнәрен билгеләү һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибе турында» V номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль хезмәткәрләрнең, муниципаль вазыйфаларны даими нигездә биләүче затларның хезмәтенә түләү системасы үзгәрүгә бәйле рәвештә, муниципаль хезмәткәрләрнең, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарында даими нигездә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга социаль гарантияләрне тәэмин итү, хезмәт өчен түләүне тәртипкә салу һәм камилләштерү максатларында, "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 22 маддәсе, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 26 маддәсе, "Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында" 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законына ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларга, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларына, контроль-хисап органнары рәисләренә, муниципаль хезмәткәрләргә хезмәт хакы түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында" 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карары, "Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә күпьеллык хезмәт өчен пенсиягә чыгу сәбәпле бер тапкыр бирелә торган кызыксындыруны түләү тәртибе турында" Нигезләмәне раслау хакында 2005 елның 29 декабрендәге 666 номерлы карары, «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасыннан пенсиягә чыгу сәбәпле Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларга бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләүне түләү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында» 2006 елның 10 июлендәге 353 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле үзидарәнең даими нигездә үз

вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларының, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 25 ноябрендәге 994 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы « Котлы Бөкәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлеге Советының 2018 елның 07 маендагы «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең даими нигездә муниципаль вазыйфа биләүче затларына акчалата бүләкләүләр, вазыйфаи айлык хезмәт хакы, айлык һәм башка өстәмә түләүләр күләмнәрен билгеләү һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибе турында» V номерлы карарына (29.09.2020 ел №II; 14.10.2024 ел №9; 04.02.2025 ел №2 карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1) «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында муниципаль вазыйфаларны даими нигездә биләүче затларга хезмәт өчен түләү күләмнәре һәм шартлары» 1 нче кушымтада авыл җирлеге башлыгының айлык акчалата хезмәт хакы күләмен 25401 сум итеп билгеләргә;

1.2) «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи айлык хезмәт хаклары күләмнәре» 2 нче кушымтасының 2 пунктында «15389,0» саннарын «16928,0»саннарына алмаштырырга;

1.3) «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Котлы Бөкәш авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренә аеруча мөһим һәм катлаулы биремнәрне үтәгән өчен премияләр түләү күләмнәре һәм тәртибе» турындагы 5 нче кушымтаның 2 пунктына түбәндәге эчтәлекле 3 нче абзац өстәргә:

"Премия Татарстан Республикасы муниципаль хезмәткәрләре спартакиадасы кысаларында спорт төрләре буенча ярышларда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләре җыелма командасы составында катнашкан муниципаль хезмәткәрләргә һәм муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга түләнә».

2. Әлеге карарның үз көчен 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә җәелдерүен билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлегенең Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Котлы Бөкәш авылы, Совет урамы, 32 йорт; Тәберде Чаллысы авылы, Совет урамы, 34 йорт; Мәмле Казаклар Чаллысы авылы, Үзәк урам, 29 йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация

челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

4.Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Котлы Бөкәш авыл җирлеге башлыгы Г.Г.Нәҗипов